РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080
тел. (факс): (84360) 2-18-67,
E-mail: Telache@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин ур., 46 йорт, Теләче авылы, 422080
тел.(факс): (84360) 2-18-67,
E-mail: Telache@tatar.ru

ОКПО 78702039 ОГРН 1061675000287 ИНН/КПП 1619004274/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**
**№ 606** — **«15» декабря 2014г.**

Теләче муниципаль районында мәгариф системасының муниципаль мониторингы турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф системасын мониторинглауны гамәлгә ашыру турында» 05.08.2013 № 662 карарын үтәү йөзеннән,

КАРАР БИРӘМ:

Теләче муниципаль районында мәгариф системасының муниципаль мониторингы турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә (Карпова Н.В.) 1 сентябрьгә кадәр кимендә бер тапкыр мониторинг үткәрүне тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары итеп йөкләргә.

А.Г. Мирсаетов

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2014 елның 15 декабрендәге 606
номерлы карарына кушымта

Теләче муниципаль районында мәгариф системасының муниципаль мониторингы турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 97 статьясындагы 4 өлеше нигезендә һәм “Мәгариф системасын мониторинглауны башкару турында” РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 05 августындагы 662 номерлы карары (алга таба - Кагыйдәләр) белән расланган Мәгариф системасы мониторингын үткәрү кагыйдәләрен 7 һәм 8 пунктларын үтәү йөзеннән эшләнгән.

1.2.Әлеге нигезләмә текстында кабул ителгән кыскартулар һәм билгеләр:

1.2.1.мониторинг - Теләче муниципаль районы территориясендә белем бирүнең торышын һәм аның нәтиҗәләрен үзгәртүнең динамикасын, Теләче муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары, мондый оешмаларда белем алучылар контингенты, Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларның уку-укыту һәм укудан тыш казанышлары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Теләче муниципаль районы муниципаль оешмаларын тәмамлаучыларның һөнәри казанышлары белән системалы стандартлаштырылган күзәтү;

1.2.2.Мәгариф бүлеге - «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе;

1.2.3.Мәдәният бүлеге - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;

1.2.4.Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге - Теләче муниципаль районы башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;

1.2.5 рәсми сайт - Теләче муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: http://tulachi.tatarstan.ru/http://tulachi.tatarstan.ru/%20

1.2.6.мониторинг уздыру өчен кирәкле белешмәләр - әлеге нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән мониторинг күрсәткечләре нигезендә мониторинг үткәрү өчен кирәкле һәм белем бирү оешмасында булган белешмәләр.

2. Мониторинг үткәрү процедуралары һәм сроклары.

2.1.Мониторингны Мәгариф бүлеге елына 1 сентябрьгә кадәр кимендә бер тапкыр гамәлгә ашыра.

2.2.Мониторинг Мәгариф бүлеге чыгара торган акт (алга таба - мониторинг уздыру турындагы акт) нигезендә мониторинг башланганчы 7 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Мониторинг үткәрү турында акт күчермәләре (мониторинг үткәрү турында акт кабул итү турында мәгълүмат) Мәгариф бүлеге буйсынуындагы мәгариф оешмаларына, шулай ук мәдәният бүлегенә һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә күрсәтелгән акт кабул ителгән көннән алып 2 эш көне эчендә җибәрелә.

Мәдәният бүлеге һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге мониторинг үткәрү турындагы акт күчермәләрен (мониторинг уздыру турындагы акт кабул итү турындагы мәгълүмат)

мәгариф бүлегеннән акт (мәгълүмат) алынган көннән алып 2 эш көне эчендә аларга буйсынучы мәгариф оешмаларына җибәрә.

Мониторинг үткәрү турындагы акт күрсәтелгән акт кабул ителгән көннән алып 2 эш көне эчендә рәсми сайтта урнаштырыла.

2.3. Мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге үз компетенцияләре чикләрендә ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан мониторинг уздыру өчен кирәкле белешмәләрне вакытында тапшыруны тәэмин итә.

2.4. Мәгариф бүлегенә буйсынучы мәгариф оешмасы мониторинг уздыру өчен кирәкле белешмәләрне мәгариф бүлегенә мониторинг үткәрү турында акт алган көннән алып 5 эш көне эчендә тапшыра (мониторинг үткәрү турында акт кабул итү турында мәгълүмат алу).

Мәдәният бүлегенә яисә яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә буйсынучы мәгариф оешмасы мониторинг уздыру өчен кирәкле белешмәләрне тапшыра, шуңа ярашлы рәвештә мәдәният бүлегенә яисә яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә мониторинг үткәрү турында акт алган көннән алып 5 эш көне эчендә тапшыра (мониторинг үткәрү турында акт кабул итү турында мәгълүмат алу).

Мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге мәгариф оешмасыннан мониторинг үткәрү өчен кирәкле булмаган белешмәләрне, белем бирү оешмасы тарафыннан җибәрелә торган белешмәләрнең нигезлелеген һәм дөреслеген раслаучы документларны (документларның күчермәләрен) соратып алырга, элек җибәрелгән белешмәләрне төгәлләштерергә хокуклы. Белем бирү оешмасы гарызнамә алган көннән алып 2 эш көне эчендә гарызнамә башкара йә гарызнамәне үтәү мөмкин булмау турында дәлилләнгән язма җавап бирә.

2.5.Мәдәният бүлеге һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге мониторинг үткәрү өчен кирәкле белешмәләр җыюны, эшкәртүне һәм анализлауны гамәлгә ашыра. Гомуми мәгълүматны мәдәният бүлеге һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге мәгариф бүлегенә җибәрәләр.

Мәдәният бүлеге һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге мәгариф бүлеге мөрәҗәгате буенча мәгариф оешмаларыннан кергән белешмәләрнең һәм документларның күчермәләрен запрос алган көннән алып 2 эш көне эчендә җибәрә.

Мәгариф бүлеге мәдәният бүлегенә һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмаларыннан кергән белешмәләрне төгәлләштерү кирәклеге турында күрсәтмәләр бирергә хокуклы. Мәдәният бүлеге һәм яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге күрсәтелгән күрсәтмәләрне 7 эш көне эчендә үтәргә тиеш.

2.6.Мәгариф бүлеге Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан һәм Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләреннән, дәүләт хакимияте органнарыннан, башка учреждениеләрдән һәм оешмалардан мониторинг үткәрү максатларында кирәкле мәгълүматны һәм документларны (документларның күчермәләрен) соратып алырга хокуклы.

Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре 7 эш көне дәвамында мәгариф бүлегенә соралган мәгълүматны һәм документларны (документларның күчермәләрен) яисә аларны тапшыруда дәлилләнгән язма кире кагуны тапшыралар.

2.7.Мәгариф бүлеге “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль мәгариф оешмаларының рәсми сайтларында урнаштырылган мәгълүматны, шулай ук мәгариф бүлегенә оешмалардан һәм гражданнардан кергән мәгълүматны, шул исәптән мониторинг үткәрү өчен кирәкле белешмәләрне һәм гомумиләштерелгән мәгълүматны, Теләче муниципаль районы муниципаль оешмалары эшчәнлеген гамәлгә ашыручы федераль статистик күзәтүнең, тикшеренүләрнең, шул исәптән социологик тикшерүләрнең, эшчәнлекләренең мәгълүматларына нигезләнеп мониторинг үткәрә.

2.8.Мәгариф бүлеге законнарда билгеләнгән тәртиптә башка оешмаларны җәлеп итеп мониторинг башкарырга хокуклы.

2.9.Мәгариф бүлеге мәгариф системасының торышына һәм үсеш перспективаларына үткәрелгән анализ нәтиҗәләре ел саен Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы билгеләгән форма буенча йомгаклау хисаплары рәвешендә рәсми сайтта (алга таба - йомгаклау хисаплары), елына кимендә 20 октябрьгә кадәр 1 тапкыр бастырып чыгарыла.

2.10.Мәгариф бүлеге ел саен, 25 октябрьдән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына йомгаклау хисапларын тапшыруны тәэмин итә.

### 3.Мониторинг күрсәткечләре.

3.1.Мониторинг Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф системасын мониторинглау күрсәткечләрен раслау турында» 2014 елның 15 гыйнварындагы 14 номерлы боерыгы белән расланган (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында теркәлгән) мәгариф системасы мониторингы күрсәткечләренең I, III бүлекләрендә һәм башка нигезләмәләрендә күрсәтелгән күрсәткечләр буенча уздырыла 06.03.2014 № 31528), алар Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары эшчәнлегенә карый. Мәгариф бүлеге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнарының күрсәтмәләре һәм киңәшләре нигезендә башка күрсәткечләр буенча да мониторинг үткәрә.